# МАНСУР

Аңарга бик уңгайсыз иде. Күзенең бер ягында еглый-еглый күзләре кызарып беткән анасы, яшенә карылып-карылып чынаягын күтәреп, үзенең башына килгән уйларын җибәрер өчен чәй эчкән кебек булып тора иде. Икенче якта атасы, зур гәүдәсе берлән идән буенда бер сүз дә дәшмәенчә, дөп-дөп басып йөри иде. Бүлмә буенда сеңелесе акыртын гына бер анасына карап, бер агасына, атасына карап, моның әйберләрен пөхтәләп-пөхтәләп букчага тутыра иде. Өйнең бүлмә тарафында тагы пырх-пырх еглау тавышы, еглый-еглый тавышлары ара-тирә «әһе-әһе» дигән тавыш берлә бүленеп-бүленеп китә иде. Мансурның үзенең дә күзенә яшь, тамагына әллә нәрсә тыгылган иде. Аның ул тыгылган нәрсәсе, ычкынып китеп, Мансурның да битен-йөзен яшь берлән юарга хәзерләнә иде. Атасы гына андый еглар төсле күренми иде. Ул, иске пишкадәм, еглаудан битәр сугышырга хәзеррәк иде. Аның кыяфәте әллә нинди ачуы килгәнне белгертә иде. Аның уйлары да үзенең моннан элек утыз биш елгы планының моның угылларына ярамавы, бу елда яшьләрнең азулары, мөталәгалары чыккан мәдрәсәдә рәхәтләнеп, бай балалары укытып, «китап карап» ятмаулары иде. Ул бу кадәр зур тәбәдделнең сәбәбен аңламый да, белми дә иде. Аңламавы, белмәве һаман Мансурларга начар иттереп каравына, «бозылган» дип уйлавына вә шул фикерен дөрест дип белүенә сәбәп була иде. Ул үзенең Сәлах хәзрәттә пишкадәм булып, шәкертләр укытып торгач, мәдрәсәдән мулла булып чыгуын, өйләнүен, балалары булуын, Мансурны тагы Сәлах хәзрәт тә пишкадәм итәргә теләп, өйдә үк «Шәрхе Габдулла», «Кавагыйд» укытып, мәдрәсәгә җибәрүләрен, мәдрәсәгә һәрвакыт җитәрлек итеп борай ярмасы, сөзмә, икмәк, богдай оны, ит, бераз акча да җибәреп торуларын уйлап, үз эченнән «баланы тәрбия» хакында үзендә бер косур да таба алмаенча, бөтен гаепне шул еллардагы гәзитәләргә, әллә нинди әкият китаплары укуга багышлый иде. Аның күз алдына бөтен гомере буе тырышып ясаган дүрт-биш дисәтинәләр алма бакчасы килә иде. Үзенең шуңарга сарыф кылган хезмәтләрен күңеленнән берәм-берәм саный иде, бакчадан килгән

файдаларны һәммәсен дә күңеленнән кичерә иде. Яшь вакытында, кечкенә вакытта Мансур бакчаларга су сибеп йөрүләре, шәкерт булгач та җәй көне бөтен гомерен шуңарга сарыф кылулары күз алдына килә иде дә, бүген Мансурның шулкадәр угылын «пишкадәм» итәргә тырышкан атасын, шәкерт вакытта бертуктамаенча вак бәлешләр җибәреп торган анасын, тагы шулкадәр күп алма бирә торган мөкәммәл бакчасын ташлап, атасыз-анасыз, бакчасыз бер җиргә «укыйм» дип китүен һич аңлый алмый иде. Моныңча, Мансурның мөталәгасе чыккан, гыйлеме бар, сабак укытып, бай балалары укытырлык вакыт булмаса, китаптан мәгънә алырлык булган. Тагы, әлхәмделиллаһ, этисе хәзрәтнең китаплары да күп, тирәсенә вак каләм берлә язган «Җәмгы»се дә бар, «Ибне Габидин» дә алдырган иде. «Мулла Җәлал» да бар, «Фараиз» да бар. Авылда һәйбәт мәдара берлән, ил картлары берлән дуст торганда җир дә бирәләр, печәне дә була. Тагы бакчадан доход та бик яхшы килә. Бот күтәрергә дә китап карап, ашап кына ятырга. Ә ул барысын да еглатып китә. Укырга китә, имеш. Мөталәга чыккач, нәрсәгә тагы укырга? Ни карадың, шуны беләсең. Тагы белмәгән мәсьәлә чыкса, мәсәлән, ай хосусында-фәләндә, мин, әлхәмделиллаһ, үзем бар, дип, иске пишкадәм угылының хәленә гаҗәпкә кала иде.

Анасы бер дә алай уйламый иде. Ул моталәгасе чыкканын да, чыкмаганын да белми, аның кирәген дә аңламый иде. Аның кайгыруы угылының «китап карап», бот күтәреп ятуы түгел, бөтенләй башка иде. Ул Мансур тугач ук угылыма бик матур кыз алып бирермез, кодалый килеп алырлар, ак оннан, эченә алма кагы кыстырып, зур сумсалар ясармын, шурпалы катлама пешерермен, пар каз куярмын, дошманнарның эчен яндырып, кыңгыраулы тройка атта «кодагый» булып китәрмен, дип уйлый иде. Аның соңында ничек килен күрендерүләрен, «кодагый» булып мунчага баруларын, килиннең төшүен, угылына әләкләп, аны кыйнатуын, килиннең ягъмурлы көннәрдә мунча ягып йөрүләрен — һәммәсен уйлый иде. Шатлана-шатлана уйлый иде. Мансур үскән саен шул эшләр кайин төсле күренә иде. Менә хәзер Мансур китәм, укыйм, ди... Анасы «кодагый» булмыймыни? Килен күрендермимени?

Башка аналар шулай «килен рәхәте» күрәләр бит, бу күрмимени? Менә анасы ни өчен кайгыра, ни өчен иртәдән бирле бертуктаусыз еглый иде. Дөрест, моңарга тагы аналык шәфкате дә катыша иде. Угылын урыслар үтермәс микән, Казан хатыннары сихерләмәс микән кебек уйлар да юк түгел иде. Ләкин болар икенче дәрәҗәдә иде.

Мансур тагы башкача уйлый иде. Ул мәдрәсәдә укыса да, «моталәгасе» чыкса да, мәдрәсәне шулкадәр вак эшкә саный иде. Ул, әтисе уйлаганча, «китап карап», авыл куштаннары берлә бер булып халыкны талап, бот күтәреп, эшләмәенчә, сугым кебек ашап ятуны, өйләнгән булып курчак төсле шылтыравыклы атларга утырып, кияү булып барып, бер танымаган, белмәгән кыз берлән бер келәткә бикләнеп ятуны шулкадәр мәгънәсез эш таба иде. Аныңча, боларның берсе дә аз гына гакылы бар кешегә һич эшләрлек түгел иде. Ул үзенең күз алдында әле гайрелниһая киткән надан, фәкыйрь, рәзил, һәр яктан хезмәткә мохтаҗ халыкны күрә иде. Шул халык шул дәрәҗә тәмугта торганда, һәм көннән-көн тәмугка китә барганда, ул матур бакчалар файдасы берлән, куштаннар киңәше берлән симез генә, йомшак кына бер кыз алып, бот күтәреп ятуны, бөтен гомерне ашау-эчүгә корбан итүне бик зур җинаятькә саный иде вә шундый вакытта шылтыравыклы атлар берлән вакыт үткәрүне гакылсызлыкка исәпли иде. Аныңча, бу вакытта һәр аңлаган, һәр белгән кеше халыкка хезмәт итәргә кирәк, һәр кеше, үзенең вак-төяк рәхәтләрен уйламаенча, халык файдасына үзен-үзе корбан кылырга кирәк иде. Мансур шулай икәнлеген аңлый иде. Шулай итүне һәркемгә фарыз дип белә иде. Шулай итү генә бугенге көндә хезмәт дип ышана иде. Шуның өчен ул үзенең пишкадәм әтисенең планын җимереп, әнисенең «кодагый» буласы килүенә дә әһәмият бирмәенчә, зур алма бакчасында кып-кызыл булып, бөтен шул тирәне матур итеп тора торган бакчага да илтифат кылмаенча «халыкка хезмәт» итәргә китә иде. Фикерен болар өчен юри әйткән кебек, хезмәтче кереп: «Атлар өлгерде» — диде. Мансурның анасы, зур сеңелесе, бигрәк тә кечкенә сеңелесе тагы кычкырышып егларга тотындылар. Мансурның да тамагына тыгылган нәрсәсе ычкынып, битен кайнар яше берлән юа башлады. Атасы да

икенче өйгә чыгып китте. Мансур бик тиз генә үзен-үзе тыеп «Хушыңыз!» — дип чыгып китте. Тигез генә чылтырап бара торган арба тавышы берлә аның алдыннан акыртын гына бу ямьсез манзарә күчеп, киләчәкләр күренә башлады. Шул «киләчәк» фикере аны бөтенләй биләп алып, ат атлаган саен үзен шул яңа тормышка якынлаша кебек хис итеп, үзенең идеалына таба китте.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Моталәга* — берәр эшне, укуны тәгалләү.

*Төбәддел*— үзгәреш.

*Косур* — кимчелек.

*Мөкәммәл* — камил

*Мәдара* —саклык, тыйнаклык, яхшы мөгамәлә.

*Хосус* — очрак, мөнәсәбәт.

*Кайин* —тормышка ашардай, булырдай

*Гайрелниһая* — чиксез.

*Рәзил* — түбән, хур.

**Мансур** — Хикәя беренче тапкыр «Таң йолдызы» гәзитәсенең 1906 ел, 23 июнь (20) санында басылган. Г.Исхакыйның
«Җыентык» (1909) исемле китабына кертелгән.
Текст «Җыентык»тан алынды.

*«Шәрхе Габдулла»* — гарәп сарыфына (морфологиясенә) фарсы телендә шәрех (аңлатмалар) биргән грамматика дәреслеге; иранлы-таҗик балалары өчен Бохарада язылып, кульязма хәлендә йөргән, анда укыган татарлар алып кайтып, Казанда берничә кат басылган, иске мәдрәсәләрдә киң таралган булган.

*«Кавыгыйд»* («Кавагыйд әл-играб») — фигыльләрнең төрләнүе кагыйдәләре. XVIII — XIX гасырларда кулъязмалар һәм басма китап булып та таралган, мәдрәсәләрдә дәреслек булып йөргән.

*«Җәмгы» («Җамигы-р-ромуз»)* — фикъһе (ислам динендә хокук белеме) китабы. Авторы: Шәмсетдин Мөхәммәд әл Куһстани әс-Самалати әл-Хорасани (1554/55 яки 1557/58 елда үлгән). Китапның кулъязма һәм басма нөсхәләре күп булган. Утыз Имәни тарафыннан китапның аңлашылмаган сүзләренә сүзлек тә төзелгән.

«*Мулла Җәлал» («Мулла Җәләл яки Шәрхе гакаиде гыйззия»)* — китап исеме.

*«Фараиз»* — («Фараизе Сираҗия» яки «Фараизе Сәҗавән- ди») — китап исеме, фикъһенең мирас бүлү мәсьәләсенә караган өлеше. Авторы: Сираҗетдин Әбутаһир Мөхәммәд бине Габдерәшит әс-Сәҗавәнди (XII гасыр).

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б. 22-25.